АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ИНСТИТУТ ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСКУССТВА
имени Г. ИБРАГИМОВА

**В.М. Усманов**

# БАШКОРТСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТАТАР ЭПИГРАФИК ҺӘЙКӘЛЛӘРЕ

## Стәрлебаш авылы

Казан
2020

**УДК 930.271**
**ББК 63.2**
**У 74**

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
*Гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә*

**Фәнни редактор**
филология фәннәре кандидаты *И.Г. Гомәров*

**Рецензентлар:**
филология фәннәре кандидаты *А.М. Ахунов,*
филология фәннәре кандидаты *А.А. Хасавнех,*
филология фәннәре кандидаты *Н.Ш. Насыйбуллина*

**Усманов В.М.**
**У 74 Башкортстан Республикасы татар эпиграфик һәйкәлләре: Стәрлебаш авылы.** – Казан: ТӘһСИ, 2020. – 208 б.; ил. 16 б.
ISBN 978-5-93091-319-4

Башкортстан Республикасы Стәрлебаш авылында XIX–XX гасырларга нисбәтле өч йөздән артык гарәп язулы ташъязма истәлек сакланып калган. Әлеге эпиграфик һәйкәлләрнең күбесе бу төбәкнең хаттатлары һәм таш язучы осталары тарафыннан эшләнгән. Китапта Стәрлебаш авылы тарихына бәйле 148 ташъязма истәлекнең текстлары, фото һәм график сурәтләре туплап бирелде.

Хезмәт Идел-Урал төбәге тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүче галимнәр, гомумән татар халкының тарихи үткәне белән кызыксынучы укучылар өчен тәкъдим ителә.

УДК 930.271
ББК 63.2

**ISBN 978-5-93091-319-4**

© Усманов В.М., 2020;
© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты, 2020

# КЕРЕШ

Бүгенге икътисади һәм иҗтимагый шартларда татар халкының үзтәңгәллеген саклау һәм яклау юлында халкыбыз төпләнеп яши торган төбәкләрнең тарихи үткәнен өйрәнү аеруча мөһим мәсьәлә. Башкортстан Республикасының Стәрлебаш авылы – шундый төбәкләрнең берсе. Октябрь инкыйлабына кадәр гыйлеммәгърифәт үзәкләреннән саналган Оренбург, Уфа, Троицк, Иж Бубый, Ташкичү, Курса кебек кала һәм салалар рәтендә Стәрлебаш авылының да лаеклы үз урыны бар.

Тарихчы галимнәрнең фикеренчә, Урал буе төбәге элек-электән татар ханлыклары яшәеше белән тыгыз бәйләнештә булган. Тарихның төрле чорларында бу җирләр Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы, Ногай Урдасы кебек татар дәүләтләре составында саналган, биредә фин-угор, төрки халыкларының ата-бабалары үзара тыгыз мөнәсәбәттә гомер кичергән[1]. Идел-Урал буйларында бүгенге татар, венгр, башкорт, ногай һәм башкалар аерым бер халык буларак тәгаенләнү юлына аяк басканнар. Ногай Урдасы җимерелү белән, аның халкының бер өлеше башкорт исәбенә күчеп, әлеге җирләрдә бүген дә яшәвен дәвам итә. Шуңа күрә бу төбәкне татарның тарихи ватаны итеп карау хакыйкатькә хилафлык китерми. Моны без XIX–XX йөз башы татар, башкорт, казакъ халыклары мәдәниятендә мөһим роль уйнаган Стәрлебаш авылы тарихына мөнәсәбәттә дә ачык күрәбез.

Стәрлебаш авылы тарихына караган һәм бүген фәнгә билгеле беренче рәсми документлар 1757 ел белән билгеләнә. Бу – юрматы башкортларының Сәгыйд Бистәсе татар сәүдәгәрләренә Стәрле

---

[1] История татар Западного Приуралья. Том I. Кочевники Великой степи в Приуралье. Татарские средневековые государства. Коллективная монография. – Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2016. – С. 9–10.

елгасының башланган урынындагы җирләрне иҗарәгә бирүе турындагы килешү кәгазе[1]. Әмма Стәрлебашның тарихын язган Мөхәммәдшакир Тукаев авылның барлыкка килү вакытын күпкә иртәрәк – 1680 еллар тирәсендә дип күрсәтә. Аның фикеренчә, Стәрлебашка Казан ягыннан күчеп килүчеләр нигез салган, соңрак аларга Сәгыйд Бистәсеннән күченгән татар гаиләләре дә өстәлгән. Бу хакта ул: «Кайбер кешеләрнең сөйләүләренә күрә, Эстәрлебашында әүвәл утлырган кемсәнәләр бераз заман торгач җирне башкортлардан арендага алганнар. Арендалары илле елга булган имеш. 1809 нчы елны 25 нче апрельдә язышкан кәгазьләре Әбүнәгыйм Мөхәммәдлатыйф углы дигән кемсәнәнең кулында бар. Аның бабасының бабасы Йосыф купес дигән кемсәнә Каргалыдан килеп сәүдә итеп, поташ забуты тоткан. Мәгълүм кәгазьне 1809 нчы елда башкортлар белән ул язышкан; ошбу кәгазь өченче мәртәбә алу имеш; һәр мәртәбәдә иллешәр елга язышканлар имеш диеп сөйлиләр. Шуңа нигезләнеп әйтсәк, башкорттан кәгазь белән 1809 нчы елдан йөз ел элек ала башлаганлар вә һәм кәгазьсез утыз еллар торган булсалар, Эстәрлебашы 1680 нче еллар чамасында нигезләнгән булса кирәк», дип яза.[2]

Иң әүвәл Стәрлебаш авылы үзенең мәктәп-мәдрәсәләре белән дан тоткан. Рәсми мәгълүматларга караганда, XIX йөзнең 80 нче елларында аларда төрле төбәкләрдән җыелган 600 тирәсе шәкерт белем алган[3]. Мәдрәсәләрне тәмамлаган шәкертләр алга таба да руханилар сыйфатында татар, башкорт, казакъ арасында дин һәм мәгърифәт таратуларын дәвам иткәннәр. Шундыйлардан казакъ ханнары Ширгази хан (1767–1845) һәм Җиһангир хан (1801–1845), мөфтиләр Габдессәләм бине Габдеррәхим (1765–1840) һәм Габделвахид бине Сөләйман (1786–1862), шагыйрьләр Шәмседдин Гобәйдуллин (Шәмседдин Зәки, 1825–1865), Гали Чокрый (1826–1889), Мифтахетдин Акмулла (1831–1895), руханилар Сәедбаттал бине Нурмөхәммәд, Зәйнулла ишан Рәсүлев (1833–1917) һ. б.ны атарга мөмкин.

---

[1] Архивные источники: Материалы по истории Башкирской АССР. – Т. 4. – Ч. 1.

[2] *Тукаев М.-Ш.* Тарихе Эстәрлебаш. – Казан: Б. Домбровский типографиясе, 1899. – Б. 2–3. *Текст бүгенге телгә яраклаштырып бирелде.*

[3] *Фархшатов М.Н.* Народное образование в Башкирии в пореформенный период 60–90-е годы XIX в. – М., 1994. – С. 59.

Стәрлебаш төбәгенең үз чорында күренекле мәгърифәт учагы булуын биредәге гарәп язулы ташъязмалар да дәлилләп тора. Авыл зиратындагы иске каберташ язулары чагыштырмача яхшы сакланган. Ташка матур итеп калкытып язылган һәм бизәп эшләнгән бу ядкярләр эстетик һәм тәрбия бирү ягыннан да гаять зур кыйммәткә ия. Биредә андый ташларның саны ике йөздән күбрәк дип исәпләнелә.

Бу ташъязма мирас, кызганыч ки, фәнни яктан тулысынча барланган һәм өйрәнелгән дип әйтеп булмый. Дөрес, узган гасырның башларында күренекле шәрекъшенаслардан В. Бартольдның[1], рухани һәм галим Р. Фәхреддиннең әлеге ядкярләр белән кызыксынуы, Стәрлебашка килеп, аларны караулары мәгълүм. Риза казыйның Стәрлебашта булуы турында тарихчы галим Р. Әмирханов түбәндәгечә искәртә: «икенче мәртәбә Диния нәзарәтенең казые итеп сайлангач, 1918 елның кышында Оренбургтан Уфага барышлый, ул Эстәрлебашның мәдрәсә һәм мәчетләрен барып күргән, күреп яки ишетеп белгән кешеләрнең каберләрен зыярәт кылган, тирән көрт булуга карамастан, иске кабер ташларын эзләп, тикшереп йөргән»[2].

Стәрлебаш авылында ике зират булуы мәгълүм. Аның берсе – иске каберлек – авылның уртасында торып калган. XVIII йөзләрдә бу урыннарда зират булганлыгын инде бүген мулла Хөсәен бине Габдрахман кабеpенә куелган язулы таш кына хәтерләтә. XX гасыр башында авыл халкы әлеге ташны яңартып куйдырткан.

Хөсәен бине Габдрахман Стәрлебашта мәчет һәм мәдрәсә салдырып, шунда шәкертләргә сабак бирә башлый, ягъни ул – бу төбәкнең гыйлем учагына әверелүенә сәбәп булган кешеләрнең беренчесе[3]. Аның исеме алдарак искәртелгән 1757 елгы иҗарә язуында да телгә алынган. Әлеге шәхес турында Мәҗит карый

---

[1] «Вакыт» газетасының 1913 ел, 9 июнь санында профессор В. Бартольдның Стәрлебашта булуы, зираттагы ташлар белән кызыксынуы турында хәбәр бирелгән: «...Андан мәрхүм Эстәрлебаш хәзрәтләрнең зиярәтләренә барыб, ташлардагы язуларны укыган. Бәгъзы бер ташларда хәзергә кадәр ачык укылыб йитми торган фарсыча язуларны профессор җәнабләре дөресләб укыган».

[2] *Әмирхан Р.* Риза Фәхреддинов – тарихчы // Мирас. – 1991. – № 12. – Б. 65.

[3] *Тукаев М.-Ш.* Тарихе Эстәрлебаш. – Казан: Б. Домбровский типографиясе, 1899. – Б. 4.



Габделмәҗид хәлфә Шәйхелислам улы Кадыйров (1881–1962)

Кадыйров үз кулъязмасында түбәндәгечә яза: «Мәрхүм Хөсәен мулланың зираты Эстәрлебаш авылының уртасында борынгы иске зират урынында. Язулы ташы һәм Эстәрлебашында Мөхәммәдшаһ ага яздырыб куймыш иде. Аның зираты икәнен кайдан белгәндер, безгә билгеле түгел. Хөсәен мулла – әүвәл мәртәбә мөфти булып килгән Мөхәммәдҗан мөфти Хөсәеновның атасыдыр»[1].

Икенче зират авыл читендә урнашкан. Стәрлебаш халкы сөйләвенә караганда, 1913 еллар тирәсендә бу каберлек Мөхәммәдхарис Тукаевның улы Габделкадыйрның матди ярдәме белән, биеклеге бер метрдан да артмаган таш дивар белән уратып алына. Зиратның борынгы урыны – аның урта тирәсендә. Моның шулай икәнлеген биредә бүгенгә кадәр сакланып калган берничә төрбә дә хәтерләтеп тора. Аларның берсе бу төбәкнең күренекле руханилары Тукаевларның гаилә каберлегенә корылган. Икенчесе атаклы ишан, нәкышбәндия тарафдары, озак еллар Стәрлебаш мәдрәсәсендә шәкертләр тәрбияләгән Әмир хәлфәгә (шәех Зәйнулла бине Хосраушир Галикәев, 1810 – 1905) мөнәсәбәтле. Өченчесе хәлфә Гали бине Ысанали әл-Казакый (?-1920)[2] һәм аның нәселе белән бәйле. Аны совет чорында Гали хәлфәнең улы мулла Габдеррахман кордырган дип сөйлиләр.

Стәрлебаш зиратының уртасында урнашкан «Хәзрәтләр каберлеге» дип аталган урын үзе бер тарихи-архитектур комплексны тәшкил итә. Биредә Стәрлебаш руханилары Габдулла бине

[1] Мәҗит карый Кадыйров кулъязмасы. 150 б. *Бу кулъязма бүген Уфада, Мәҗит карыйның нәсел дәвамчысы Зөһрә ханым Вәлиуллованың шәхси архивында саклана.*

[2] Метрикә дәфтәрләрендәге мәгълүматларга караганда, бу шәхес чыгышы белән Әстерхан төбәгеннән, чиркәс ыругының кыргыз-казакъ кавеменнән.

Гаделшаһ, Нигъмәтулла, Мөхәммәдхарис, Мөхәммәдхаррас, Хәбибулла, Габдулла, Гобәйдулла Тукаевлар, Зәйнулла Галикәев, Гали Ысанали улы, Хафизмөхәммәд бине Нариман, Фәхреддин бине Хөснемөтәвәллид, Гаид бине Фазлулла, Әбүнәгыйм бине Мөхәмммәдьяр, Габдрахман Айдабулов һәм башка мөхтәрәм затларның кабер ташлары бүген дә кадерләп саклана.



Габдеррәхим Галиев (1867–1966)

Стәрлебашта бик борынгы эпиграфик һәйкәлләр булмаса да (иң әүвәлгесе 1844 елга карый), биредә таш язу һөнәренең барлыкка килүе, аның сәнгать кимәленә күтәрелә алуы төрле сәбәпләр белән бәйләнгән. Шундыйлардан, югарыда әйтеп үткәнебезчә, Стәрлебашның гыйлем-мәгърифәт үзәге саналуын, анда сәләтле хаттат-каллиграф һәм таш язучы осталарның эшләвен, бу төбәктә эпитафия өчен уңайлы табигый материалның булуын билгеләргә мөмкин.

Стәрлебаш тирәсендә өч урында таш карьерлары билгеле. Беренчесе – төзелеш эшләре өчен комташ күп чыгарылган Кардон тавында. Икенчесе – Гөмбазы ягындагы Бакырчагылтау дип аталган урында. Өченчесе – халык телендә «Калячный чокыр» дип йөртелгән җир. Анда чыга торган кызгылт төстәге йомшак эшкәртелүчән таш төзү эшендә дә, кабер ташларын ясауда да еш кулланылган. Ләкин җирле хаттатлар өчен Яшерган ташыннан да яхшы таш булмаган. Олы яшьтәге кешеләрнең сөйләүләре буенча, Яшерган ташчылары известь ташны Таштаудан һәм Айтуган авылына якын урнашкан тау сыртларындагы карьерлардан чыгарганнар. Яшерган ташлары җир астыннан чыгарылгач та, дымлы көенчә бик йомшак булу сәбәпле, кипкәнче «шалкан кебек» җиңел киселгән. Аны күп очракта ике метр озынлыктагы зур пычкы (30 нчы елларда аны «стахан пычкысы» дип атаганнар) белән дүрткел формада кискәннәр, балта белән эшкәрткәннәр, каләм белән



Габдрахман Айдабулов
(1881–1972)

язганнар һәм махсус өтергеләр ярдәмендә чокып нәкышьләгәннәр. Эш барышында таш кибеп катыланып китсә, язарга уңайсыз була башласа, аны берникадәр вакыт су эченә салып тотканнар яисә өстенә су сибеп торганнар һәм шундый рәвештә ташны йомшартып, әүвәлге хәленә кайтарганнар.

Стәрлебаш авылының үзендә генә төрле һөнәр ияләре белән бергә дистәгә якын таш язучы оста яшәгән. Алар арасыннан исеме алдарак искәртелгән Гали хәлфә бине Ысанали әл-Казакый, мулла Габдулла бине Мөхәммәдхарис Тукаев, хаҗи Габдеррәхим Галиев, мулла Габдрахман Айдабулов, мулла Ләтыйфулла бине Зәйнулла Галикәев, Габделвахид бине Әбүнәгыйм, Габделмәҗид бине Әбүнәгыйм, Хәлим Габделмәҗид улы Монасыйпов һ.б. исемнәрне атый алабыз. Әмма кайбер осталарның исем-шәрифләре бүген дә фәнгә билгесез булып кала килә, чөнки һәр хаттат та үзе язган ядкяргә кул-тамгасын салуны мәҗбүри санамаган.

Стәрлебаш осталары язган эпиграфик һәйкәлләр тирә-яктагы авылларда, күрше төбәкләрдә (Стәрлетамак һәм Уфа зиратларында), хәтта җирле осталар ясаган кайбер ядкярләр Урта Азия якларында да булуы мәгълүм.

Гали хәлфә улларыннан Габдеррәхим Галиев бу сәнгать төренең иң күренекле вәкилләреннән санала. Ул ясап калдырган ташларның исәбе берничә йөз. 1898 елгы ташъязмаларның берсендә «әл-мөнәкъкаш әл-хаҗи Габдеррәхим бине Гали хәлфә әл-Казакый…», ягъни «хаҗи Габдеррәхим Гали әл-Казакый хәлфә угылы нәкышьләде…» дигән сүзләр язылган. Габдеррәхим 1887 – 1897 еллар арасында хаҗга барган һәм шул вакытта берничә ел Төркиядә укыган. Истанбул шәһәрендә төрек солтанына каршы

оештырылган фетнәләр вакытында кулга алынган һәм чит ил кешесе булу сәбәпле генә үлем җәзасыннан котылып калган. Совет хакимияте дәверендә 1960 елга кадәр таш язу эше белән шөгыльләнүче төп хаттат Стәрлебаш авылында фәкать ул гына булган.



Габделвахид Әбүнәгыйм улы Монасыйпов

Гали хәлфәнең икенче улы – Габдрахман да Стәрлебаш мәдрәсәсендә төпле белем алган, шул ук мәдрәсәдә хәлфәлек иткән, Түбән мәчеттә мулла вазифаларын үтәгән. Совет чорында мәдрәсәләр ябылгач, берничә ел үз өендә балалар укытып йөргән. Аннары сөргенгә сөрелгән, Беломор каналын төзүдә катнашкан. Стәрлебашлыларның сөйләүләренә караганда, ул таш кисү эше белән махсус рәвештә шөгыльләнмәгән, ясаган эшләре дә мәрхүм булган якын туганнарына гына куелган.

Җирле осталар үз эшләрен татар эпиграфикасының Болгар чорларыннан ук килгән сәнгати традицияләренә нигезләнеп башкарганнар. Палеографик үзенчәлекләре буенча караганда, Стәрлебаш ядкярләре, нигездә, гарәп язуының нәсех төре белән язылган. Сөлес, нәстәгъликъ, рөкъга һәм чәчкәле куфи кебек язу стильләре мондагы ташъязмаларда күренми диярлек. Дөрес, Габделвахид һәм Габделмәҗид Монасыйповлар кулы белән эшләнгән берничә үрнәктә кирпечтән төзелгән корылмаларны бизәкләүдә еш кулланыла торган «гади куфи» (строительный куфи) язуы файдаланылган. Әмма бу ядкярләр берникадәр соңрак чорга – XX гасыр башына карыйлар. Классик нәсех язуыннан аермалы буларак, үзенчәлекле язу тарызында башкарылган хәлфә Гаид бине Фазлулланың кабер ташын да аерым билгеләп үтәргә мөмкин.

Аңлашыла ки, эпиграфик һәйкәлләрне ясату матди чыгымнар белән бәйләнгән. Еш очракта кабертешлар яздырту эшенең бәясе ишек, тәрәзә кебек нәрсәләр ясатуга бәрабәр булган.

Эпитафияләрнең күп өлеше калкытып ясау ысулы белән башкарылган, таштагы хәреф-бизәкләр күпертеп ясалган. Аларның декоратив бизәлешендә ниндидер катлаулы геометрик яисә үсемлек орнаментлары кулланылмаган диярлек, бары тик берничә үрнәктә генә чәчәк, үсемлек-яфрак кебек элементларны күрергә мөмкин. Әмма бу үзенчәлек әлеге истәлекләрнең сәнгати бизәлеш дәрәҗәсен киметми, чөнки Стәрлебаш ташъязма сәнгать әсәрләрендә төп нәкышьләү алымы булып, гарәп язуының үз бизәлеше, ягъни эпиграфик орнамент хезмәт итә.

Ташъязма ядкярләр арасында, берничә истәлекне исәпләмәгәндә, ыру тамгалары кебек рәсем элементлары очрамый. Кайбер үрнәкләрдә, төп эпитафик тексттан тыш, гарәпчә, фарсыча яки татарча язылган шигъри юллар да күренә. Мисалга хәлфә Әбүнәгыйм бине Мөхәммәдьяр кызы каберенә куелган таштагы шигъри юлларны китерергә мөмкин:

*Әй балам, рух мөкаддәсең җәннәт әгълия очдымы,*
*Бер тотарга кыймас тәннәреңне рәхимсез ләхет кочтымы?*
*Һич тынмаслык хәсрәт ялкыннары үстердең син минем бәгъремә,*
*Мәңге, мәңге онытылмаслык итеп таш утыртам синең кабреңә...*

Кайбер матур язулы эпитафия авторларының исемнәрен ачыклау авыр мәсьәлә булып кала. Аңлашыла ки, култамгасы күрсәтелмәгән үрнәкләрне чит хаттатлар түгел, Стәрлебаш руханиларыннан саналган шәех-муллалар, мәзин-хәлфәләр язган дип фараз итә алабыз.

Әлеге җыентыкта Стәрлебаш ташъязмаларыннан хронологик тәртиптә 146 берәмлек эпитафик үрнәк укучылар игътибарына тәкъдим ителә. Безнең тарафтан бу ядкярләрнең график прорисовкалары башкарылды, эпитафияләре укылды. Ташъязма сурәтләренең алгы ягы *А*, уң ягы *Б*, арткы ягы *В*, сул ягы *Г* хәрефләре белән тамгаланды. Шулай ук китапның кушымта өлешендә Стәрлебаштан читтә мәрхүм булган бу төбәк тарихы белән бәйле берничә күренекле шәхеснең ташъязмалары да урын алды. Китаптагы төсле кушымтада ташъязмаларның фотосурәтләре дә бирелә.

*В.М. Усманов,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Язма һәм музыкаль мирас үзәге фәнни хезмәткәре*

## СТӘРЛЕБАШ ТАШЪЯЗМАЛАРЫ

### 1. Хөсәен Габдрахман улына куелган кабер ташы (борынгы иске зират)

Игътибар итсәгез, әлеге вакытта, Эстәрлебаш авылының Чапаев урамындагы (беренче номерлы өй урнашкан) йортның бакчасында кыргый ташлар белән уратып алынган каберлек бар. Аның өстендә сирень агачлары үсеп утыра һәм каберлекнең бер ягында гади рәвештә язылган ташъязма да бар. – Бу нинди каберлек? – дигән сорауга, йорт хуҗасы бер апа (үзенең ата-бабалары сөйләгәннәрдән): «монда бик дәрәҗәле һәм укымышлы кеше күмелгән һәм бу урында элек борынгы зират булган» – дип аңлатма бирде. Димәк, югарыдан аңлашылганча, 1680–1800 еллар дәверендә Эстәрлебаш авылының каберстаны (зираты) элекке «Урта мәсҗед» һәм мәдрәсәләр биләмәләре кырында урнашкан булган.

«1720 нче еллардан соң Эстәрлебашында мәсҗид салыныб әүвәл мәдрәсә бина кылыб дәрес башлаган кемсәнә Хөсәен мелла Габдрахман углыдыр. Мәрхүм әүвәл мәртәбә Эстәрлебашында мәсҗид бина кылыб җомга укый башлаб, бу көндә Эстәрлебашындагы минбәр таягы ошбу Хөсәен хәзрәтдән калган таякдыр. Шул минбәр таякына язган язуы бар: Хөсәен бине Габдрахман дип язган; 1870 нче елларда бу таякга йөз илле ел бар дип нәкыль идәләр иде. Бик белеб сүзләгән кешедән мәзкүр Хөсәен мелла әүвәл мәртәбә мөфти булып килгән, Мөхәммәджан мөфти Хөсәеновның атасыдыр. Мөхәммәджан мөфти олугъ Екатерина саниянең әмер һөмаюны илә 1789 нчы елда мөфти булып килгән. Ошбу юкарыда мәзкүрләргә бинаән Хөсәен мелла тәхминән 1720 нче елларда Эстәрлебашында дәрес башлаган, шул вакытларда мәсҗид һәм мәдрәсәләр бина кылынган. Имди Эстәрлебаш мәдрәсәсенең




тарихыны 1720 нче еллардан хисаб кылырга ярый. Ошбу Хөсәен мелла хәзрәтләре каию елларда вафат улдыгыны белгән кешеләр булмады, вә ничә ел дәрес әйткәне беленмәде; әммакә салих вә галим әмере билмәгъруф кеше улган дию нәкыль идәләр…»[1]

Ташъязма чокып (уеп) язылган.

(١) كفا بالموة واعظا (٢) هذه التربت الشريف (٣) للمتوفى داملا مرحوم (٤) حسين
بن عبد (٥) الرحمن الستر لى (٦) باشنده ... (٧) قوپث يكى يوز (٨) يل چماسنده
(٩) ١١٢٥ نچى سنه ١٩١٥ نچى (١٠) ٢١ آپريل

Югарыдагы эпитафияне без түбәндәгечә бәян итәбез: бу ташъязма, 1915 елның 21 нче апрель көнендә язылып[2], дамелла (һәм Эстәрлебаш купесы) мәрхүм Хөсәен бине Габдрахманның каберенә куелган; аңлашылганча, бу сәүдәгәр ике йөз ел чамасы элек (1120 нче һижри, ягъни милади исәп буенча 1708/1709 елларда) бирегә килеп төпләнгән.

---

[1] *Тукаев М.-Ш.* Тарихе Эстәрлебаш. – Казан, 1899. – Б. 5.

[2] Мәҗид карый Кадыйров кульъязма истәлекләрендә: «Мөхәммәдшаһ ага яздырыб куймыш иде» дигән мәгълүмат беркетеп калдырылган.


كفا بالموة واعظا
طهذه التربة الشريف
للمتوفي دا املامرحوم
حسين بن عبد
الرحمن الستنرلی
باشنده
فوت يكي يوز
يل چماسنده
١١٣٥ نجی

1=A

Өстәмә мәгълүмат:

1) Мулла Хөсәен бине Габдрахман, Сәгъид Хәйалин һәм Котлыгмөхәммәд Тәфкилев (1675−1766) кебек билгеле шәхесләр, бер-берсе белән бик яхшы таныш булганнар дип уйларга кирәк;

2) Кыргыз-казакъ (һәм «Шәһре Каргалы») якларына бара торган сәүдә юлларының бер тармагы Стәрлебаш аша үткәндер дип фараз итәргә кирәк.

## 2. Мулла Гаделшаһ Габдулла улына бәйле төрбә. 1812 ел

Тукаевларның мавзолееннан төньяк-көнчыгыштарак кыргый ташлардан салынган каберлек бар (ихатасының биеклеге чама белән 60 см). Төрбәнең кабер ташы юк, ләкин, бу корылма, фәкать, мулла Гаделшаһныкы булгандыр дигән фикердә калабыз.

Аның хакында Ризаэддин Фәхреддин «Асыллары Бөре өязендәге Богдан авылыннан. Гаделшаһ бине Габдулла Эстәрлебаш авылында имам вә мөдәррис булып, 80 яшенә ирешеп, 1227/1812 елда дөнья куйган. Кабере мәгълүм», «…хайваннардан саклау өчен каберем тирәли кирпеч йә таштан бер бина кордырыгыз» дип язган[1].

## 3. Гыйсмәтулла Биктимер улы Тукаевка куелган кабер ташы, 1844 ел

Алгы ягында (уйма язулы):

| | |
|---|---|
| ١) اعوذ بالله | 1) әгүзү билләһи |
| ٢) من الشيطان الرجيم | 2) минәш-шәйтанир-раҗим |
| ٣) بسم الله الرحمن الرحيم | 3) бисмиллаһир-рахманир-рахим |
| ٤) لا اله الا الله | 4) лә иләһә илләл-лаһ |
| ٥) محمد رسول الله | 5) Мөхәммәд рәсүлүл-лаһ |

---

[1] *Фәхреддин Ризаэддин.* Асар. 1 том. – Казан: Рухият, 2006. – Б. 133–134.


اعوذ بالله
من شيطان الرجيم
بسم الله الرحمن الرحيم
لا اله الا الله
محمد رسول الله
مرحوم عصمت الله

3=A

| | |
|---|---|
| ٦) مرحوم عصمت الله | 6) мәрхүм Гыйсмәтулла |
| ٧) بن بيكتمر المرحى | 7) бине Биктимер әл-Мәрхи |
| ٨) ١٨٤٤ سنده اپريل | 8) 1844 сәнәдә апрель- |
| ٩) ننك ٢٠ نچى يومنده | 9) нең 20 нче йәүмендә |

Эпиграфик һәйкәл кызгылт көрән төстәге комташтан ясалган. Үлчәмнәре: 18×30×90 см.

## 4. Тукаевлар төрбәсе диварына беркетелгән беренче ташъязма. 1871 ел

Бу таш корылма Каргалы төрбәләре рәвешендә салынган. Алгы ягында (калку язулы):

١) هذه التربة الشريفة للشيخ الامام لافاضل الكامل خليفة الشيخ قطب الاقطاب السالك فى طريق النقشبندية
٢) نياز محمّد مند نيازقلى التركمانى البخارى ابن محمد حارث محمد نعمت الله بن بكتمر السترلى باشى رحمه الله تعالى رحمةً واسعةً
٣) ...
٤) ...

1) һәзиһи әт-төрбәт әш-шәрифәт әш-шәйех әл-имам әл-фазыйль әл-кямил халифәт әш-шәйех көтбел-әкътаб әс-салик фи тарикъ эн-нәкышьбәндия
2) Нияз-Мөхәммәд мәнд Ниязколый әт-Төркмани әл-Бохари… Мөхәммәдхарис… Нигъмәтулла бине Биктимер әл-Эстәрлебаши (рәхимәһә Аллаһу Тәгалә рәхмәтән васыйгатән[1])
3) …[2]
4) …

Кабер ташы Яшерган авылындагы («Таштау» карьерыннан чыгарылган) известьняк таштан ясалган.

[1] Аңа Аллаһның киң рәхмәте булсын.
[2] Эпиграфик һәйкәлнең өченче һәм дүртенче сәтырында фарсы телендә фәлсәфи эчтәлекле шигъри юллар язылган.



4=A



5=A

Эпитафиянең төгәл кайчан һәм кем тарафыннан язылуы билгесез (кятиб – хәлфә Гали әл-Казакый (? – 1920) булуы ихтимал), ләкин шунысы мәгълүм: һәйкәл 1870 – 1871 еллардан соң гына бина кылынган.

Үлчәмнәре: 20×81×118 см.

## 5. Шәех Нигъмәтулла һәм аның улы Мөхәммәдхарис хәзрәт. Тукаевлар төрбәсе диварына беркетелгән икенче ташъязма. 1870–1871 еллар

Алгы ягында (калку язулы):

١) هذه التربة المباركة للشيح التربة والعانى ... الصَّمد خَليفة محمد الشيخ عبيد الله
٢) البخارى الامام ... عبد الله محمد خارث بن نعمة الله السترلى باشى النقشبندى توفى سنة سبع و ثمانين و ... والف رحمهم الله تعالى
٣) يَا وقفًا بقبرى متفكًا بامرى بالامسى كنت مثلك غدى تصير مثلى الفاتحة
٤) ...

1) һәзиһи әт-төрбәт әл-мөбарәкәт лил-шәйех әт-төрбәт вә әл-гани … әс-самад хәлифәт Мөхәммәд әш-шәйех Гобәйдулла
2) әл-Бохари әл-имам … Габдулла Мөхәммәдхарис бине Нигъмәтулла әл-Эстәрлебаши ән-нәкышьбәнди тәвәффи сәнәтү вә сәбгә вә сәманин вә миъәтин вә әлфин[1] рәхимәһемү Аллаһу Тәгалә
3) йа вакыйфән би-кабри мөтәфәккирән би-әмри бил-әмси күнтү мисликә гадән тәсайир мисли әл-фатихат
4) …[2]

---

[1] 1287 һиҗри сәнә 1870–1871 елларга тәңгәл килә. Ядкяр Яшерган ташыннан ясалган, үлчәмнәре: 75×115 см.

[2] Бу урында гарәп телендә алты юлдан гыйбрәт шигъри әсәр язылган.

## 6. Мөхәммәдхәррас Тукаевка куелган кабер ташы, 1871 ел

Алгы ягында (калку язулы):

١) كفى بالموت واعظا هذه التربة الشريفة المبارك للشيخ
٢) الفاضل الكامل محمد حراث خليفة الشيخ عبيدالله بن محمد نيازقلى
٣) النقشبندى بن الشيخ نعمة الله الاسترلى باشى المتوفى فى السنة المسيحية
٤) ١٨٧١ نويابر ٠٣ رحمهم الله واسعة وطاب الله ثراهم و جعل الجنة مثواهم ٦٢ ياشنده

1) кәфә бил-мәүти вагыйзән һазиһи әт-төрбәт әш-шәрифәт әл-мөбарәк әш-шәйх

2) әл-фазыйль әл-кямил Мөхәммәдхәррас хәлифәт әш-шәйх Гобәйдулла бине Мөхәммәднияз Колый

3) ән-нәкышьбәнди бине әш-шәйх Нигъмәтулла әл-Эстәрлебаши әл-мөтәвәффи фи әс-сәнәти мәсихиять

4) 1871 нуябер 30 рәхимәһе Аллаһү рәхмәтән васыйгатән таййәбә Аллаһу сәраһү вә җәгаләл – җәннәти мәсваһу
62 йәшендә

Тышның кабыргасындагы калкытып язылган текст укырлык хәлдә түгел.

Эпитафиянең авторы кятиб Гали хәлфә бине Ысанали әл-Казакый булуы ихтимал. Эпитафия Яшерган ташыннан ясалган.

Ядкяр, ике өлешкә сынып, табигый рәвештә җимерелә бара һәм кадер-хөрмәтсез җир өстендә аунап ята.

Үлчәмнәре: 16×48×160 см.

## 7. Баймөхәммәд Әхмәдҗан улы әл-Казакыйга куелган кабер ташы, 1871–1872 еллар

Алгы ягында (калку язулы):

١) اشهد ان لا اله الا الله و اشهد ان محمد عبد و رسول
٢) هذه التربة للمرحوم المتوفى كردارى روغى جباعى طائفه سى
٣) بايمحمد ابن احمدجان القزقى الجايقى ابن تلانچى مريد الشيخ



6=A




7=A

٤) محمدحارث رحمهما الله تعالى فى سنة و ماءتين و ثمانية
٥) و ثمانين من الهجرة النبوية

1) әшһәдү-ән лә иләһә иллә Аллаһы вә әшһәдү иннә Мөхәммәдән габдүһү вә рәсүлүһү
2) һәзиһи әт-төрбәт әл-мәрхүм әл-мөтәвәффи Кәрдари ругы Җәбагый тайфәсе
3) Баймөхәммәд ибне Әхмәджан әл-Казакый әл-Җаекый ибне теләнче мөрид әш-шәйх
4) Мөхәммәдхарис рәһим һома Аллаһы Тәгалә фи сәнәтә өлеф вә маитин вә сәманият
5) вә сәманин мин әл-һиҗрия[1] ән-нәбүять

Баймөхәммәд хәлфә Әхмәджан улы «Хан мәдрәсәсе»ндә казакъ шәкердләренә гыйлем тәхсил кылган.

Ядкяр Яшерган ташыннан ясалган.

Үлчәмнәре: 9×50×100 см.

## 8. Шаһмөхәммәдкә куелган кабер ташы, 1871 ел

Ядкяр кызгылт көрән төстәге комташтан ясалган, текст тулысынча сакланып калмаган.

Алгы ягында (гарәп язулы текст, уеп башкарылган):

Шаһмөхәммәд бине Шаһ…, Русияһ, вафат 1871 нче йылда…

## 9. Йосыф Хәсән улына куелган кабер ташы, 1871 ел

Ядкяр Яшерган ташыннан ясалган.

Алгы ягында (гарәп язулы текст):

мәрхүм Йосыф бине Хәсән, вафат 1871 йылда.

---

[1] Һиҗри 1288, миляди 1871–1872 елларга тәңгәл килә.

## 10. Мөхәммәдләтыйф Монасыйп улына куелган кабер ташы, 1872 ел

Алгы ягында (калку язулы):

| | |
|---|---|
| ۱) کفی بالموت واعظا | 1) кәфә бил-мәүти вагыйзән |
| ۲) هذه التربة الشريفة | 2) һәзиһи әт-төрбәт әш-шәрифәт |
| ۳) للمتوفى المرحوم محمد لطيف | 3) лил-мөтәвәффи әл-мәрхүм Мөхәммәдләтыйф |
| ۴) بن مناسيب الاسترلى باشى | 4) бине Монасиб[1] әл-Эстәрлебаши |
| ۵) فى ۱۸۷۲ سنة | 5) фи 1872 сәнәти |

Ташъязманың авторы кятиб Габдулла Тукаев дип фараз ителә.
Үлчәмнәре: 11×48×110 см.

## 11. Мөхәммәдкәрим Гаделшаһ улына куелган кабер ташы, 1872 ел

Алгы ягында (уеп язылган):

| | |
|---|---|
| ۱) هذه التربة الشريفة | 1) һәзиһи ә әт-төрбәт әш-шәрифәт |
| ۲) للمتوفى المرحوم الحاج | 2) лил-мөтәвәффи әл-мәрхүм әл-хаҗ |
| ۳) محمد كريم بن | 3) Мөхәммәдкәрим[2] бине |
| ٤) عد الشاه فى | 4) Гаделшаһ фи |
| ۵) فى ۱۷۸۲ سنة ۶۴ ياشنده | 5) фи 1872 сәнәти 64 йәшендә |

Үлчәмнәре: 12×45×120 см.

---

[1] Йосыф исемле сәүдәгәрнең нәселен дәвам итүчеләр.
[2] Шәҗәрә язуы: Мөхәммәдкәрим бине Гаделшаһ бине Габдулла бине Богдан.



10=A


هذه التربة الشريفة
للمتوفى المرحوم الحاج
محمد كريم بن
عبد الشافي
في شعبان ١٨٧٢

11=A

## 12. Хафиз-Мөхәммәд Нуриман улына[1] куелган кабер ташы, 1872 ел

| | |
|---|---|
| ١) هذه التربة الشريفة | 1) һәзиһи әт-төрбәт әш-шәрифәт |
| ٢) العالم العامل حافظ محمد بن | 2) әл-галим әл-гамил Хафиз-Мөхәммәд бине |
| ٣) نور ايمان اليخشى كان مدرسًا | 3) Нуриман әл-Яхшый … |
| ٤) فى عصر الشيخ الحرمين | 4) фи гасыр әш-шәйх хаҗел-хәрәмәен |
| ٥) محمد حارث و توفى سنة فى ١٢٨٩ | 5) Мөхәммммәдхарис вә тәүвәффи фи сәнәти 1289[2] |
| ٦) رحمه الله تعالى | 6) рәхмәтуллаһи Тәгалә |

Ташъязманың авторы кятиб Габдулла Тукаев дип фараз ителә.
Үлчәмнәре: 10×49×160 см.

## 13. Габделкаһир Котлугзаман улына куелган кабер ташы, 1876 ел

Алгы ягында (калку язулы):

١) باسم تعالى المتوفى المرحوم المحتاج الى
٢) ر ... المسمى عبد القاهر ولد قتلوع زمان فى شهر ذوا
٣) لقعدة فى قرية استرلى باش و فى ١٨٧٦ سنة عفر
٤) الله ذنوبه و ستر عيوبه امين

1) би-исми Тәгалә әл-мөтәвәффи әл-мәрхүм мохтаҗ илә
2) р[аббиһи] әл-мөсәммә Габделкаһир вәләд Котлугъзаман фи шәһри зөл-
3) лькагдә карйәт Эстәрлебаш вә фи 1876 сәнәти гафәрә
4) Аллаһу зөнубиһи вә сәттәрә гуюбиһи әмин

Үлчәмнәре: 12×45×60 см.

---

[1] Стәрлебаш авылында гомер кичергән мәшһүр хәлфәләрнең берсе (Минзәлә өязендәге Байсар төбәгеннән).

[2] Милади 1872 ел.



12=A



13=A

## 14. Хәдичә Белоусованың кабер ташы, 1877 ел

Бу тарихи истәлек Стәрлебаш төбәгендәге камил кимәлдә башкарылган хөсне хат үрнәкләренең берседер. Ядкяр имам-хатыйб менла Габдулла Тукаевның җәмәгате – Исәнбай кызы Хәдичәнең (?–1877) каберенә куелган. Ташъязма гарәп телендә башкарылган, авторы – хаттат Габдулла Тукаев.

Алгы ягында (калку язулы):

| | |
|---|---|
| ١) هذه التربة الشريفة | 1) һәзиһи әт-төрбәт әш-шәрифәт |
| ٢) للمتوفة المرحومة الموصية | 2) лил-мөтәвәффәт әл-мәрхүмәт әл-мусыяти |
| ٣) ... بی بی حديچه بنت | 3) би-сәләс малиһа биби Хәдичә бинте |
| ٤) ایسانبای زوجة امام خطیب | 4) Исәнбай, зәүҗәте имам хатыйб |
| ٥) منلا عبد الله الاسترلی باشی | 5) менла Габдулла әл-Эстәрлебаши |
| ٦) فی السنه الف و ... وسبع و سبعین | 6) фи әс-сәнәти әлф вә сәманмиъәтин вә сәбгә вә сәбгыйн[1] |

Үлчәмнәре: 14×58×160 см.

## 15. Лотфулла Тукаевка куелган кабер ташы, 1877 ел

Алгы ягында (калку язулы):

| | |
|---|---|
| ١) هذه التربة الشريفة | 1) һәзиһи әт-төрбәт әш-шәрифәт |
| ٢) للمتوفی المرحوم الامام | 2) лил-мөтәвәффи лил-мәрхүм әл-имам |
| ٣) لطف الله بن الشیخ | 3) Лотфулла бине әш-шәйх |

[1] Мең сигез йөз җитмеш җиденче елда.



14=A


هذه التربة الشريفة
للمتوفى المرحوم الامام
لطف الله بن الشيخ
محمد حراث اشتل
الخطاب ارجح وهو ابن
ثمانية وثلثين فى سنة ١٨٧٧

15=A

| | |
|---|---|
| ٤) محمد حراث امتثل | 4) Мөхәммәдхәррас имтәсәлә |
| ٥) ارجع و هو ابن ثانية | 5) иржәгъ вә һуа ибне саният |
| ۶) و ثلثين فى سنة ١٨٧٧ | 6) вә сәлясийн фи сәнәти 1877[1] |

Әлеге кабер иясе хакында «Тарихе Эстәрлебаш» китабында түбәндәге мәгълүматлар китерелә: «Мөхәммәдхәррас хәзрәтдән соң урынына угълы Лотфулла мәхдүм имам булды. Лотфулла мәхдүм 1878 нче елда август аенда вафат булды»[2].

Үлчәмнәре: 10×48×130 см.

## 16. Мулла Хафизеддин улына куелган кабер ташы, 1880 ел

Алгы ягында (уеп язылган):

| | |
|---|---|
| ١) تربة | 1) төрбәт |
| ٢) الطالب العلم النافيع | 2) әт-талибел-галим ән-нафигъ |
| ٣) مطيغ الله ابن ملا | 3) Мотыйгулла ибне мулла |
| ٤) حافظ الدين قوناققلى | 4) Хафизеддин Кунакколый |
| ٥) توفى ١٨٨٠ سنه | 5) тәвәффи 1880 сәнә |

Ядкяр кызгылт көрән төстәге ком ташыннан ясалган, әкренләп җимерелә бара.

Үлчәмнәре: 13×45×50 см.

---

[1] *Иржәгъ вә һуа ибне саният вә сәлясийн фи сәнәти 1877* – 1877 елда 32 яшендә вафат.

[2] *Тукаев М.-Ш.* Тарихе Эстәрлебаш. – Казан, 1899. – Б. 14.


تربة
الطالب العلم النافع
لطيف الله ابن ملا
حافظ الدين
توفي ١٨٨٥

16=A

## 17. Гаделшаһ Исмәгыйль улына куелган кабер ташы, 1883 ел

Алгы ягында (уйма язулы):

| | |
|---|---|
| ١) لا اله الا الله محمد | 1) лә иләһә иллә Аллаһу Мөхәммәд |
| ٢) رسول الله المرحوم | 2) рәсүлуллаһ әл-мәрхүм |
| ٣) عدلشاه بن اسماعيل | 3) Гаделшаһ бине Исмәгыйль |
| ٤) مات ١٨٨٣ نچى يلده | 4) матә 1883 нче йылда |

Үлчәмнәре: 8×40×60 см.

## 18. Мөхүбҗәмал Монасыйп кызына куелган кабер ташы, 1884 ел

Алгы ягында:

Мәрхүмә Мөхүбҗәмал бинте Монасиб вафат 1884 нче йылда 14 нче апрельдә.

## 19. Маһитаб Гобәйдулла кызына куелган кабер ташы, 1884 ел

Алгы ягында (уйма язулы):

| | |
|---|---|
| ١) كفى بالموت واعظا | 1) кәфә бил-мәүти вагыйзән[1] |
| ٢) هذه تربة | 2) һәзиһи төрбәт |
| ٣) المرحومة | 3) әл-мәрхүмәт |
| ٤) ماه تاب | 4) Маһитаб |
| ٥) بنت | 5) бинте |
| ٦) عبيد الله | 6) Гобәйдулла |
| ٧) برسوانباشى | 7) Бөрсуанбаши |
| ٨) ١٨٨۴ نچى يل | 8) 1884 нче йыл |
| ٩) نويابرده | 9) ноябрьдә |
| ١٠) ٣٥ ياشنده وفات | 10) 35 йәшендә вафат |

Үлчәмнәре: 12×30×120 см.

---

[1] *Кәфә бил-мәүти вагыйзән* – Үлем – зирәк укытучы.


لا اله الا الله محمد
رسول الله المرحوم
عدلشاه بن اسماعيل
مات ١٨٨٣ انجى بلده

17=A




19=A

## 20. Газизә Искәндәр кызына куелган кабер ташы, 1880 ел

Алгы ягында (калку язулы):

| | |
|---|---|
| ١) كفى بالموت واعظا | 1) кәфә бил-мәүти вагыйзән[1] |
| ٢) هذه تربة | 2) һәзиһи төрбәт |
| ٣) الشريفة المرحومة | 3) әш-шәрифәт әл-мәрхүмәт |
| ٤) ببى عزيزه ابنة | 4) биби Газизә ибнәт |
| ٥) اسكنْدر اكلايف | 5) Искәндәр Әгъляев |
| ٦) زوجة ايشان | 6) зәүҗәте ишан |
| ٧) ملا محمد حراث | 7) мулла Мөхәммәдхәррас |

Сул ягында (калку язулы):

١٨٨٠ نچى سنه ميلادى ل نچى ديكابرده رحلت قيلدى

1880 нче сәнә миляди 5 нче декабрьдә рихләт кылды

Үлчәмнәре: 11×38×140 см.

## 21. Мәзин Әхмәдшаһ кызына куелган кабер ташы, 1885 ел

Алгы ягында (гарәп язуында):

мәрхүмә Хафизә бинте Әхмәдшаһ мөәззин зәүҗәте Әбелгата 1885 нче йылда вафат…

[1] *Кәфә бил-мәүти вагыйзән* – Үлем – зирәк укытучы.



20=А, Г



22=A

## 22. Мулла Габдрахман Еникеевның кабер ташы, 1885 ел

Сәүдәгәр Габдулла Еникеевнең улы Габдрахман каберенә куелган ядкяр. Аерым бер мәгълүматлар буенча Габдрахман (1861–5.02.1885) чахотка авыруыннан вафат булган.

Алгы ягында (калку язулы):

| | |
|---|---|
| ١)هذه تربة شريفة للمتوفى | 1) һәзиһи төрбәт шәрифәт лил-мөтәвәффи |
| ٢) المرحوم المغفور طالب | 2) әл-мәрхүм әл-мәгъфүр талиб- |
| ٣) العلم ملا عبد الرحمن | 3) ел-гыйлем[1] мулла Габдеррахман |
| ٤) بن عبد الله كنكفى ١٨٨٥ | 4) бине Габдулла Кенәкәфи 1885 |

Үлчәмнәре: 12×34×145 см.

## 23. Мулла Җәляледдин Сираҗеддин улына куелган кабер ташы, 1887 ел

Алгы ягында:

мәрхүм менла Җәляледдин бине Сираҗеддин
1887 нче йылда вафат.

## 24. Билаледдин Фәйзулла улына куелган кабер ташы, 1888 ел

Алгы ягында:

мәрхүм Билаледдин бине Фәйзулла вафат 1888 нче йылда
60 йәшендә.

---

[1] Талибел-гыйлем – гыйлем эстәүче, шәкерт, студент.


هذه تربة المتوفي
المرحومة صاحبة
زوجه يوسف
بنت خير الدين
سنه في ١٨٨٧

25=A

### 25. Маһишәһ Хәйреддин кызына куелган кабер ташы, 1887 ел

Алгы ягында (уйма язулы):

| | |
|---|---|
| ١) هذه تربة للمتوفة | 1) һәзиһи төрбәт лил-мөтәвәффәт |
| ٢) المرحومه بى بى ماهيشه | 2) әл-мәрхүмә биби Маһишәһ |
| ٣) زوجهء يوسف | 3) зәүҗәи Йосыф |
| ٤) بنت خير الدين | 4) бинте Хәйреддин |
| ٥) ١٨٨٧ نچى سنه | 5) 1887 нче сәнә |

Үлчәмнәре: 9×37×70 см.

### 26. Әхмәдгали Ибраһим улына куелган кабер ташы, 1888 ел

Алгы ягында (уйма язулы):

| | |
|---|---|
| ١) لا اله الا الله محمد رسول الله | 1) лә иләһә иллә Аллаһу Мөхәммәд рәсүлүллаһ |
| ٢) هذه تربة المرحوم | 2) һәзиһи төрбәтел-мәрхүм |
| ٣) احمد على بن ابراهيم | 3) Әхмәдгали бине Ибраһим |
| ٤) ١٨٨٨ نچى يل ٣٠ نچى اوكتبر | 4) 1888 нче йыл 30 нчы октябрь |
| ٥) صالح آولندان الا | 5) Салих авылындан әл-Э- |
| ٦) سترلى باشى | 6) -стәрлебаши |

Үлчәмнәре: 11×40×75 см.

### 27. Габдрахман Тукаевка куелган кабер ташы, 1888 ел

Алгы ягында (калку язулы):

| | |
|---|---|
| ١) هذه التربة الشريفة | 1) һәзиһи әт-төрбәт әш-шәрифәт |
| ٢) للمتوفى المرحوم عبد الرحمن | 2) лил-мөтәвәффи әл-мәрхүм Габдеррахман |


لا اله الا الله محمد رسول الله
هذه تربة المرحوم
احمد علی بن ابراهیم

26=A




27=A

| | |
|---|---|
| ٣) بن الشيخ محمدحراث | 3) бине әш-шәйх Мөхәммәдхәррас |
| ٤) امتثل الخطاب ارجع | 4) имтәсәлә әл-хитаб арҗәга |
| ٥) و هو ابن ثمانية و عشرين | 5) вә һуа ибн сәмания вә гыйшрин[1] |
| ٦) ... | 6) … |

Ташъязма ике өлешкә сынып ватылган, өске ягы кадер-хөрмәтсез җир өстендә ята.

Үлчәмнәре: 9×46×120 см.

## 28. Фәтхулла Мортаза улына куелган кабер ташы, 1890 ел

Алгы ягында (калку язулы):

| | |
|---|---|
| ١) كفى بالموت واعظا | 1) кәфә бил-мәүти вагыйзән[2] |
| ٢) هذه التربة | 2) һәзиһи әт-төрбәт |
| ٣) الشريفة المتوفى | 3) әш-шәрифәт әл-мөтәвәффи |
| ٤) المرحوم فتح الله | 4) әл-мәрхүм Фәтхулла |
| ٥) بن مرتضى القزانى | 5) бине Мортаза әл-Казани[3] |
| ٦) وفات ٢ نچى اپريلده ١٨٩٠ نچى يلده | 6) вафат 2 нче апрельдә 1890 нчы йылда |

Сул ягында (калку язулы:)



٧١ یاشنده 71 яшендә

Үлчәмнәре: 9×40×100 см.

---

[1] *Вә һуа ибн сәмания вә гыйшрин* – 28 яшендә иде.

[2] *Кәфә бил-мәүти вагыйзән* – Үлем – зирәк укытучы.

[3] Казан губернасы Чистай өязе Иске Әлмәт волосте Яңа Әлмәт авылының ясаклылар социаль катламыннан.




28=A

## 29. Габденнасыйр Хөсәен улына куелган кабер ташы, 1890 ел

Алгы ягында (калку язулы):

| | |
|---|---|
| ١) ١٨٩٠ سنه | 1) 1890 сәнә |
| ٢) عبد الناصير حسين [اوغلى] | 2) Габденнасыйр Хөсәен [углы] |

Арткы ягында (уйма язулы):

| | |
|---|---|
| ١) ١٨٦٠ نچى يلده | 1) 1860 нчы йылда |
| ٢) مارطننك ٣ سنده | 2) мартның 3 сендә |
| ٣) المرحوم المتوفى | 3) әл-мәрхүм әл-мөтәвәффи |
| ٤) داملا موءذين عبد | 4) дамулла мөәззин Габд- |
| ٥) النصير حسين او | 5) -еннасыйр Хөсәен у- |
| ٦) على ياوش ... قريهء | 6) -глы Яуш [князь] карьяи |
| ٧) نور | 7) нәүвәрә |
| ٨) الله مرقده | 8) Аллаһу мәркадәһу |
| ٩) ... | 9) … |

Сул ягында ( уйма язулы):

| | |
|---|---|
| ١٨٠١ مارطننك ... | 1801 мартның … |

Дамулла мәзин Габденнасыйр (1801–1890) бине хаҗи Хөсәен (?–1892) бине князь Ибраһим Дашкин 1860 елда Яуш авылыннан Стәрлебашына белем эстәргә дип килгән булган.

Үлчәмнәре: 13×45×115 см.

## 30. Хөсәен Дашкинга куелган кабер ташы, 1892 ел

Алгы ягында (уйма язулы):

| | |
|---|---|
| ١) هذه تربة | 1) һәзиһи төрбәт |
| ٦) للمتوفى المرحوم | 2) лил-мөтәвәффи әл-мәрхүм |




29=A



29=B




30=A

| | |
|---|---|
| ٣) الحاج الحرمين حسين | 3) әл-хаҗел-хәрәмәен Хөсәен |
| ٤) بن ابراهيم ١٨٩٢ | 4) бине Ибраһим 1892 |

Ташъязма ике өлешкә сынып ватылган, өске ягы җир өстендә ята.

Үлчәмнәре: 10×48×80 см.

## 31. Бәһаведдин Җәляледдин улына куелган кабер ташы, 1892 ел

Алгы ягында (уйма язулы):

| | |
|---|---|
| ١) هذه تربة للمتوفى | 1) һәзиһи төрбәт лил-мөтәвәффи |
| ٢) المرحوم بها الدين | 2) әл-мәрхүм Бәһаведдин |
| ٣) بن جلال الدين ١٨٩٢ | 3) бине Җәляледдин 1892 |
| ٤) نچی سنه ده وفات | 4) нче сәнәдә вафат |
| ٥) ٣ نچی دیکابرده | 5) 3 нче декабрьдә |
| ٦) ... | 6) … |

Үлчәмнәре: 11×30×120 см.

## 32. Сәяхеддин Шиһабеддин улына куелган кабер ташы, 1894 ел

Алгы ягында (уйма язулы):

| | |
|---|---|
| ١) كفى بالموت واعظا | 1) кәфә бил-мәүт вагыйзән |
| ٢) هذه  التربة الشريفة | 2) һәзиһи әт-төрбәт әш-шәрифәт |
| ٣) للموت  فى المرحوم طالب العلم | 3) лил-мөтәвәффи әл-мәрхүм талибел-гыйлем |
| ٤) سياح الدين بن شهاب الدين | 4) Сәяхеддин бине Шиһабеддин |
| ٥) المسكاوى ٢٠ ياشنده ١٨٩۴ ... | 5) әл-Мәскәви 20 йәшендә 1894 сәнәдә |

Үлчәмнәре: 10×45×55 см.

---

[1] *Кәфә бил-мәүти вагыйзән* – Үлем – зирәк укытучы.




31=A




32=A

## 33. Әбүнәгыйм Хөсәен улына куелган кабер ташы, 1894 ел

Алгы ягында (калку язулы):

| | |
|---|---|
| ١) كفى بالموت وعظا | 1) кәфә бил-мәүти вәгыйзән |
| ٢) هذه التربة الشريفة | 2) һәзиһи әт-төрбәт әш-шәрифәт |
| ٣) المتوفى المرحوم ابو نعيم | 3) лил-мөтәвәффи әл-мәрхүм Әбүнәгыйм* |
| ٤) بن حسين ۴۶ یاشنده | 4) бине Хөсәен 46 йәшендә |
| ۵) ۱۸۹۴ سنه سنتبر ۱۴ | 5) 1894 сәнә сентябрь 14 |

Шәҗәрә язуында кабер хуҗасының исеме Әбүнәгыйм бине Мәхмүд бине Мәкъсуд дип күрсәтелгән. 1848–14.09.1894.

Үлчәмнәре: 11×38×125 см.

## 34. Гобәйдулла Әфлятун улына куелган кабер ташы, 1896 ел

Алгы ягында:

мәрхүм Гобәйдулла Әфлятун углы, 1896 нче йылда 17 нче сентябрьдә 56 йәшендә вафат

## 35. Мулла Гаид Фазлулла улына куелган кабер ташы, 1897 ел

Алгы ягында (калку язулы):

| | |
|---|---|
| ١) هذه تربة الشريفة | 1) һәзиһи төрбәт әш-шәрифәт |
| ٢) اَفضل الحلفاء | 2) әфзаль әл-хүләфәи |
| ٣) منلا عيد بن | 3) менла Гаид бине |
| ٤) فضل الله | 4) Фазлулла |
| ۵) المتوفى فى ۱۸۹۷ سنة | 5) әл-мөтәвәффи фи сәнәти 1897 |
| ۶) ۷۸ یل عمر سوردی | 6) 78 ел гомер сөрде |



33=A



35=А, Г




36=A




36=B

Сул ягында (калку язулы):

| | |
|---|---|
| قليدى برْجا اوچ شيخ ننك حدمتن | кылды барча өч шәйехнең хидмәтен |

Эпиграфик һәйкәл ике өлешкә сынган.
Үлчәмнәре: 16×40×115 см.

### 36. Хәбибулла Мөхәммәдхарис улы Тукаевка куелган кабер ташы, 1897 ел

Алгы ягында (калку язулы):

| | |
|---|---|
| ١) هو الله الباقى | 1) һуа Аллаһ әл-Бакый |
| ٢) هذه التربة الشريفة | 2) һәзиһи әт-төрбәт әш-шәрифәт |
| ٣) للشيخ المدرس حليفة الشيخ | 3) лил-шәйх әл-мөдәррис хәлифәт әш-шәйх |
| ٤) السالك طريق فى النقشبندية... | 4) әс-салик тарикъ фи нәкышбәндияти |
| ٥) محمد ذاكر بن محمد شريف الاوركانجى | 5) Мөхәммәдзакир бине Мөхәммәдшәриф әл-Үргәнҗи |
| ٦) حبيب الله بن الشيخ محمد حارت بن | 6) Хәбибулла бине әш-шәйх Мөхәммәдхарис бине |
| ٧) الشيخ نعمة الله الاستر لى باشى | 7) әш-шәйх Нигъмәтулла әл-Эстәрлебаши |

Икенче ягында (калку язулы):

١) امتثل الحطاب تولد فى سته...١٢٨ الهجرة ...
٢) و الحطاب ارجع فى سنه ١٣١۴ ...
٣) المنقش الحاج عبد الرحيم بن على خلفه ...
٤) ...

1) имтәсәлә әл-хитаб [тәвә-]лләд фи сәнәти 128… әл-һиҗрәти[1]
2) вә хитаб ирҗәгъ фи сәнәти 1314 …[2]

---

[1] Хәбибулла Тукаев миляди исәп буенча 1856 елда дөньяга килгән.
[2] Миляди исәп буенча 1897 елда вафат булган.

3) әл-мөнәккашь әл-хаҗи Габдеррәхим бине Гали хәлфә
әл-Казакый
4) апрель 7, 1888

Эпиграфик һәйкәл ике өлешкә сынган, өске ягы җир өстендә ята. Үлчәмнәре: 12×56×160 см.

### 37. Габделкәбир Динмөхәммәд улына[1] куелган кабер ташы, 1899 ел

Алгы ягында (калку язулы):

| | |
|---|---|
| ١) كفى بالموت واعظا | 1) кәфә бил-мәүти вагыйзән |
| ٢) هذه التربة الشريفة | 2) һәзиһи әт-төрбәт әш-шәрифәт |
| ٣) للمتو فى المرحوم العلم | 3) лил-мөтәвәффи әл-мәрхүм әл-галим |
| ٤) عبد الكبير بن دينمحمد الارسلانى | 4) Габделкәбир бине Динмөхәммәд әл-Арслани |
| ٥) فى سنة الف و ثلثماءة و سبع عشرة | 5) фи сәнәти әлеф вә сәләсамиәт вә сәбгъ гашәрәт |
| ٦) من هجرة من عليه افضل التحية | 6) мин һиҗрәт мән галәйһе әфзаль әт-тәхият[2] |

Үлчәмнәре: 12×50×150 см.

### 38. Мулла Ярулла Габдеррәшид улына куелган кабер ташы, 1899 ел

Алгы ягында (калку язулы):

| | |
|---|---|
| ١) كفى بالموت واعظا | 1) кәфә бил-мәүти вагыйзән |
| ٢) هذه التربة الشريفة | 2) һәзиһи әт-төрбәт әш-шәрифәт |

[1] Бу шәхес тумышы белән Тәтер-Арслан авылыннан. Ул Стәрлебаш мәдрәсәсендә хәлфәлек иткән, вафатыннан соң шунда җирләнгән.

[2] Һиҗри ел исәбе белән 1317 елда. Миляди ел исәбе белән 1899–1900 елларга туры килә.



38=A

| | |
|---|---|
| ٣) للمتوفى المرحوم منلاجار الله | 3) лил-мөтәвәффи әл-мәрхүм менла Җарулла |
| ٤) بن عبد الرشيد القاراملى | 4) бине Габдеррәшид әл-Карамалы |
| ٥) الكنالى فى سنة ١٨٩٩ | 5) әл-Кенәли фи сәнәти 1899 |

Үлчәмнәре: 12×40×160 см.

## 39. Шангәрәй Галиевкә куелган кабер ташы, 1899 ел

Алгы ягында (калку язулы):

| | |
|---|---|
| ١) كفى بالموت واعظا | 1) кәфә бил-мәүти вагыйзән |
| ٢) هذه التربة الشريفة | 2) һәзиһи әт-төрбәт әш-шәрифәт |
| ٣) للمتوفى المرحوم شانكراى | 3) лил-мөтәвәффи әл-мәрхүм Шангәрәй |
| ٤) بن محمد على علييف | 4) бине Мөхәммәдгали Галиев |
| ٥) ١٨٩٩ ... | 5) 1899 … |

Үлчәмнәре: 10×34×80 см.

## 40. Әбнәгыйм Мөхәммәдләтыйф улына куелган кабер ташы, 1900 ел

Алгы ягында (уйма язулы):

| | |
|---|---|
| ١) لا اله الا الله محمد | 1) лә иләһа иләллаһу Мөхәммәд |
| ٢) رسول الله هذه التربة | 2) рәсүлүллаһ һәзиһи әт-төрбәт |
| ٣) ابنعيم بن محمد لطيف | 3) Әбнәгыйм бине Мөхәммәдләтыйф |
| ٤) مات ١٩٠٠ نچى يلده ٦٧ ياشده | 4) матә[1] 1900 нче йылда 67 яшьтә |

Үлчәмнәре: 8×50×50 см.

[1] *Матә* – вафат булды, үлде.


هذه التربة الشريفة
للمتوفي المرحوم شانكراى
بن محمد علي عليف

39=A



40=А

## 41. Чынгали улы мулла Солтангәрәйгә куелган кабер ташы, 1901 ел

Алгы ягында (калку язулы):

١) هذه التربة الشريفة المتوفى المرحوم الشاب
٢) الاديب طالب العلم منلا سلطانكراى ابن چنعلى
٣) القزاقى قد امتثل الخطاب ارجع و هو ابن لثنتين و عشرين
٤) فى سنة الف و ثلثماءة و ثمان عشرة من هجرة
٥) النبى صلّى الله تعالى عليه و سلم
٦) و اليوم الثانى من ذى الحجه و سنة ١٩٠١ من المسيحية

1) һазиһи әт-төрбәт әш-шәрифәт әл-мөтәвәффи әл-мәрхүм әш-шаб
2) әл-әдиб талибел-гыйлем менла Солтангәрәй ибне Чынгали
3) әл-Казакый кад имтәсәлә әл-хитаб ирҗәгъ вә һуа ибнү иснәтәен вә гыйшрин
4) фи сәнәти әлеф вә сәләсммиәт вә сәман гашрәт мин һиҗрәт
5) ән-нәби саллалаһу Тәгалә галәйһи вәс-сәлләм
6) вә әлйаүм әс-сани мин зөлхиҗҗәт[1] вә сәнәт 1901 мин әл-мәсихият

---

[1] Пәйгамбәребез (Аллаһ Тәгаләнең аңа сәламе ирешсен) һиҗрәтеннән соң 1318 елда, зөлхиҗҗәнең икенче көнендә.



41=А, Б, Г

Сул ягында (калку язулы):

